ГЛАВА КЕМЕШ-КУЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.61, с. Кемеш-Куль,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422147

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӨМЕШ-КҮЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 61 нче йорт, Көмеш-Күл авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422147

тел.(факс): (85563) 2-46-38; e-mail: KemKul.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

КАРАР | Постановление

N 9 | 14.12.2022 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлегенә гражданнардан коррупциячел юнәлешле фактлар буенча килгән мөрәҗәгатьләр белән эшләү тәртибен раслау турында

"Россия Федерациясендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон, "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы, "Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында" 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 статьясы, "Көмеш-Күл авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлегенә гражданнардан коррупциячел юнәлешле фактлар буенча килгән мөрәҗәгатьләр белән эшләү тәртибен расларга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Көмеш-Күл авыл җирлеге сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

Авыл җирлеге башлыгы: И.Н.Сәләхетдинов

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Көмеш-Күл авыл җирлеге башлыгының
12.12.2022 ел, № 9 карарына
1 нче кушымта.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлегенә гражданнардан коррупциячел юнәлешле фактлар буенча килгән мөрәҗәгатьләр белән эшләү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлегенә (алга таба - авыл җирлеге) кергән коррупция һәм янау фактлары, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен кысу, хезмәт тәртибенә карата таләпләрне бозу, шулай ук хезмәт урыныннан явызларча файдалану билгеләре булган авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләре кылган башка гамәлләр, шулай ук муниципаль хезмәт вазыйфалары булып тормаган һәм авыл җирлеге эшчәнлегенә техник тәэмин итүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләр тарафыннан башкарылган коррупциячел юнәлеше фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләрен(алга таба – мөрәҗәгать) карау үзенчәлекләрен билгели.

Башка затларга карата шундый ук фактлар турында белешмәләрне үз эченә алган мөрәҗәгатьләр "Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 3 өлеше нигезендә мөрәҗәгатьләрдә куелган мәсьәләләрне хәл итү алар компетенциясенә керә торган тиешле органга яисә тиешле вазыйфаи затка җибәрелергә тиеш.

2. Коррупциячел юнәлешле фактлары буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча эшнең хокукый нигезен түбәндәгеләр төзи:

- 2008 елның 25 декабрендәге N 273-ФЗ "Коррупциягә каршы тору турында"гы Федераль закон;

- 2006 елның 2 маендагы N 59-ФЗ "Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында"гы Федераль закон;

-"Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында" 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.

3. Мөрәҗәгать "Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" Федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда теркәлә һәм карала. Мөрәҗәгатьтә әзерләнә, кылына торган яисә кылынган хокукка каршы гамәлләр, аларны әзерләүче, башкаручы, яки башкарган зат турындагы белешмәләр булганда, мөрәҗәгать аларның компетенцияләре нигезендә хокук саклау органнарына җибәрелергә тиеш.

4. Мөрәҗәгатьне караганда, андагы белешмәләрне, шулай ук гражданның шәхси тормышына кагылышлы белешмәләрне аның ризалыгыннан башка тарату рөхсәт ителми. Карала торган мәсьәләнең барлык шартларын ачыклаганчы мөрәҗәгатьтә куелган

мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә кергән вазыйфаи затка язма мөрәҗәгатьне җибәрү гражданның шәхси тормышына кагылышлы белешмәләрне таратуга керми.

5. Коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүче вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә хезмәт мәгълүматларының һәм конфиденциаль характердагы белешмәләрнең сакланышы өчен җаваплы.

6. Билгеләнгән тәртиптә теркәлгән мөрәҗәгатьләр эш башкару һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы гражданнары мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлегенә хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясенә карау өчен тапшырыла.

7. Мөрәҗәгать җибәргән гражданга җавап әзерләү авыл җирлегенең җаваплы заты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8. Мөрәҗәгатьтә җаваплы затка карата коррупция юнәлешендәге фактлар турында белешмәләр булган очракта, ул аны карауда катнашмый. Мондый мөрәҗәгатьне карау Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының эш башкару һәм гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла.

9. Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү өчен авыл җирлегенең җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан коррупциячел юнәлештәге фактларны үз вакытында ачыклау һәм бетерү максатында коррупциячел юнәлештәге фактлар буенча гражданнарның мөрәҗәгатьләре системалы рәвештә (елга кимендә 1 тапкыр) анализлана һәм гомумиләштерелә.